**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын индексацияләү турында**

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының 23 статьясындагы 12 өлеше нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең акчалата гомуми хезмәт хакы турында» 2006 елның 5 апрелендәге ПУ-133 номерлы (Татарстан Республикасы Президентының 2006 елның 25 декабрендәге ПУ-583 номерлы, 2010 елның 15 июлендәге ПУ-459 номерлы, 2011 елның 22 апрелендәге ПУ-234 номерлы, 2011 елның 20 июнендәге ПУ-360 номерлы, 2011 елның 13 октябрендәге ПУ-646 номерлы, 2012 елның 20 февралендәге ПУ-126 номерлы, 2012 елның 20 августындагы ПУ-681 номерлы, 2013 елның 5 августындагы ПУ-715 номерлы, 2013 елның 23 ноябрендәге ПУ-1143 номерлы, 2014 елның 17 гыйнварындагы ПУ-34 номерлы, 2014 елның 7 августындагы ПУ-761 номерлы һәм 2016 елның 25 мартындагы ПУ-285 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) һәм Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты Аппаратында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләгән затларның вазыйфаи окладлары турында» 2006 елның 5 апрелендәге ПУ-142 номерлы (Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 13 мартындагы ПУ-128 номерлы, 2010 елның 19 апрелендәге ПУ-238 номерлы, 2010 елның 21 июнендәге ПУ-394 номерлы, 2010 елның 8 сентябрендәге ПУ-596 номерлы, 2011 елның 13 апрелендәге ПУ-210 номерлы, 2011 елның 5 октябрендәге ПУ-620 номерлы, 2011 елның 30 ноябрендәге ПУ-774 номерлы, 2012 елның 13 августындагы ПУ-649 номерлы, 2012 елның 19 октябрендәге ПУ-880 номерлы, 2013 елның 18 гыйнварындагы ПУ-31 номерлы, 2013 елның 1 февралендәге ПУ-74 номерлы, 2013 елның 18 маендагы ПУ-420 номерлы, 2013 елның 10 августындагы ПУ-754 номерлы, 2013 елның 14 октябрендәге ПУ-1014 номерлы, 2013 елның 30 октябрендәге ПУ-1065 номерлы, 2013 елның 14 декабрендәге ПУ-1214 номерлы, 2014 елның 1 октябрендәге ПУ-949 номерлы, 2015 елның 17 октябрендәге ПУ-995 номерлы һәм 2016 елның 21 октябрендәге ПУ-950 номерлы указлары нигезендә кертелгән

үзгәрешләре белән) указлары нигезендә билгеләнгән һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын индексацияләү турында» 2007 елның 3 декабрендәге ПУ-647 номерлы, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын индексацияләү турында» 2008 елның 3 октябрендәге ПУ-490 номерлы, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын индексацияләү турында» 2012 елның 13 августындагы ПУ-646 номерлы һәм «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын индексацияләү турында» 2013 елның 26 сентябрендәге ПУ-941 номерлы указлары нигезендә арттырылган (индексацияләнгән) акчалата бүләкләүне 2017 елның 1 октябреннән 1,049 тапкыр арттырырга (индексацияләргә).

2. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең, алар биләгән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларына туры китереп, айлык вазыйфаи окладларын күтәргәндә (индексацияләгәндә) аларның күләме, шулай ук айлык һәм башка өстәлмәләр һәм өстәмә түләүләр күләме арттыру ягына тулы бер сумга кадәр түгәрәкләнергә тиеш, дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына әлеге Указны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны Татарстан Республикасы бюджетында тиешле финанс елына каралган бюджет ассигнованияләре күләмендә финанслауны тормышка ашырырга.

4. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ ГОМУМИ БҮЛЕК
АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2017 ел, 11 август
№ ПУ-668